ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
IV чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
IV созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
14.02.2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№42-09

**Актаныш муниципаль районының муниципаль мөлкәт реестрларын алып бару тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 51 статьясындагы 5 өлеше, РФ Финанс министрлыгының «Муниципаль мөлкәт реестрларының җирле үзидарә органнары тарафыннан алып бару тәртибен раслау турында» 2023 елның 10 октябрендәге 163н боерыгы, Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы муниципаль мөлкәте реестрларын алып бару тәртибен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.
2. Актаныш муниципаль районы Советының «Актаныш муниципаль районының муниципаль милек реестры турында»2006 елның 15 декабрендәге 11-7 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru.бастырып чыгарырга.

Актаныш муниципаль районы Советы рәисе Л.Р.Зарипов